Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлеге Кычытканлы авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

КАРАР

«22» ноябрь 2022 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 22 ноябрендә узган: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Кычытканлы авыл җирлегенең Кычытканлы авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан тыш, 2023 елда 3200 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлеге торак пунктында су башнясы сатып алу һәм урнаштыру;
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлегендә сүүткәргеч торбаларның аерым участокларын алыштыру һәм суүткәргеч челтәрләрне ремонтлау;
-Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлегендә янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру;
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлеге торак пункты чикләрендә юлларны ремонтлау һәм карап тоту;
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авылында парк зонасын төзекләндерү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 340 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 177 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 156 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 21 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлеге Кычытканлы авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Кычытканлы авыл җирлегенең Кычытканлы авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан тыш, 2023 елда 3200 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлеге торак пунктында су башнясы сатып алу һәм урнаштыру;

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлегендә суүткәргеч торбаларның аерым участокларын алыштыру һәм суүткәргеч челтәрләрне ремонтлау;

-Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлегендә янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру;

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлеге торак пункты чикләрендә юлларны ремонтлау һәм карап тоту;

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авылында парк зонасын төзекләндерү» мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Кычытканлы авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче Ф.Р. Сабиров

Кычытканлы авыл җирлеге башлыгы Ф.Р. Сабиров